| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 569-70/тэ-2023

«Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №5-105/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 13.12.2023 № 57-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2024 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2024 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020-2024 елларга тарифлар билгеләү хакында» 11.12.2019 №5-105/тэ карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №531-93/тэ-2022 карары керткән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 5-105/тэ
карарына 1 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2023 № 569-70/э-2023
карары редакциясендә)

## 2020-2024 елларга «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1 278,93 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1 278,93 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 31.06.2021 кадәр | 1 278,93 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 30.12.2021 кадәр | 1 313,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 313,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1 395,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1 405,42<*> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 405,42 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1 877,18 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <**> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1 534,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1 534,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 31.06.2021 | 1 534,72 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2021 башлап 30.12.2021 кадәр | 1 576,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 576,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1 674,48 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1 686,50 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 1 686,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 252,62 | - | - | - | - | - |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 № 531-93/тэ-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге